Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2019 нчы елның 25 нче октябре 269№

Советның 2016 нчы елның 17 нче ноябрендәге
63 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районында муниципаль хезмәт
турындагы Нигезләмә хакында" карарына
үзгәрешләр кертү турында

2007 нче елның 2 нчę мартындагы 25-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законга, 2013 нче елның 25 нче июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Советның 2016 нчы елның 17 нче ноябрендәге 63 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4.1.3 нче пунктның 6 нчы пунктчасында “мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы” сүзләрен "индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ формасында да" сүзләренә алмаштырырга;

- 6.3.5 нче пунктның 2 нче абзацындагы "ә стажның дәвамлылыгы һәм айлык түләүләр әлеге кодекс нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук дәрәҗәләрдә исәпкә алына" сүзләрен "ә сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый актында билгеләнгән күләмдә исәпкә алына" сүзләренә алмаштырырга;

2.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстембә калдырам.

4. Карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Никошин А.Ф.

Совет Алькеевского муниципального района РТ